РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 23 » 10 2024 ел №953

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 14.03.2022 елның №173 санлы карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән заказчыларның үзара эшчәнлеге тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 05.04.2013 елның № 44-ФЗ санлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 елның № 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 14.03.2022 елның №173 санлы карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар

өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән заказчыларның үзара эшчәнлеге тәртибенә (алга таба — Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.5 пунктындагы 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контракт – товарны китерү, эшне башкару, хезмәт күрсәтү (шул исәптән күчемсез мөлкәтне сатып алу яисә мөлкәтне арендалау) предметы булган һәм Федераль законның 05.04.2013 елның № 44-ФЗ санлы 15 статьясындагы 1, 2.1, 4, 4.1, 4.3 һәм 5 өлешләре нигезендә бюджет учреждениесе, дәүләт яисә муниципаль унитар предприятие яисә башка юридик зат тарафыннан төзелгән дәүләт яисә муниципаль контракт йә граждан-хокукый шартнамә;»;

1.2. Тәртипнең 1.5 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Заказчы – дәүләт яки муниципаль заказчы йә 05.04.2013 елның №44-ФЗ санлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 һәм 2.1 өлешләре нигезендә сатып алуларны гамәлгә ашыручы бюджет учреждениесе, дәүләт, муниципаль унитар предприятиеләр;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы З.З. Гыйбадуллина

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05